ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.03.2024 Балык Бистәсе штп. № 47пи

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләрен (гаилә әгъзаларын) « Хоккей һәм тимераякта фигуралы шуу буенча спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенә барган өчен түләүдән азат итү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 №647 Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 20.10.2022 №1122, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында «20.10.2022 №1122 карарлары, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрбиләр һәм затларның, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнарның, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнарның, махсус хәрби операциясе уздырыла торган зонага командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләрен (гаилә әгъзаларын) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Хоккей һәм тимераякта фигуралы шуу буенча спорт мәктәбе" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет

учреждениесенең боз аренасына (массакүләм шуу, тимераякны арендалау) бару, тренажер залында шөгыльләнү өчен түләүдән азат итәргә.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Хоккей һәм тимераякта фигуралы шуу буенча спорт мәктәбе" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенә тәкъдим итәргә:

2.1.1 пунктта күрсәтелгән ташламаларны хәрби комиссариатның гражданның махсус хәрби операция уздыру зонасында хәрби хезмәттә булуы турындагы белешмәсе һәм шәхесне раслаучы документ нигезендә бирергә;

2.2 гражданнар хәрби хезмәттән кайткан очракта ташламаның гамәлдә булуын туктатуны контрольдә тоту максатыннан хәрби комиссариат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тотарга.

3.Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 16 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы И.З. Шакировка йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов